**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Республика ярдәм фонды турында

Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән кредит һәм башка финанс оешмалары эшчәнлегеннән зыян күргән затларга, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән (гамәл кылмавыннан) зыян күргән затларга ярдәм оештыру максатларында, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының фонд оештыру-хокукый формасында Республика ярдәм фонды төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Республика ярдәм фонды советының кушымтада бирелүче составын расларга.

3. Республика ярдәм фондына «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруда катнашучы махсуслаштырылган оешма функцияләрен үтәү вәкаләте бирергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасы исеменнән Республика ярдәм фондын гамәлгә кую функциясен башкаручы вәкаләтле органын билгеләргә;

Республика ярдәм фондын төзү һәм аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле карарлар кабул итүне тәэмин итәргә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 29 май
№ ПУ-447

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «29» маендагы
ПУ-447 номерлы Указы белән
расланды

**Республика ярдәм фонды советы**
**составы**

| | |
|---|---|
| Нуретдинов<br>Айрат Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, Совет рәисе |
| Агиев<br>Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Демидов<br>Сергей Анатольевич | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары |
| Кудряшев<br>Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасары |
| Ибраһимов<br>Рөстәм Сәгыйть улы | «Татарстан Республикасы Үзәк депозитарие» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сибгатуллин<br>Рөстәм Рәфкать улы | Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры |
| Фетюхин<br>Марат Владимирович | Казан (Идел буе) федераль университетының экология, хезмәт хокукы һәм гражданлык процессы кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Шәмсетдинов<br>Рамил Равил улы | Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе урынбасары – җир-мөлкәт мөнәсәбәтләрен координацияләү һәм үстерү бүлеге мөдире |

______________